| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ХУҖА ХӘСӘН<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2022г. Хуҗа Хәсән ав. №12

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 08 августындагы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» Хуҗа Хәсәнавыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 08 августындагы 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтада:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Керемнәрнең баш администраторлары, Исемлеккә үзгәрешләр кертү кирәк булган очракта, алар барлыкка килгән көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, бюджет классификациясе коды булган исемлеккә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне (килешү буенча) Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, бюджет классификациясе коды исемен, керем чыганагын администрацияләү өчен нигез булып торучы норматив хокукый актлар исемлеген җибәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле дүртенче пункт өстәргә:

«4. Тәкъдимнәрне карау йомгаклары буенча Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (килешү буенча) күрсәтелгән тәкъдимнәр кергән көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча исемлеккә үзгәрешләр кертү турында боерык кабул итә, баш тарткан очракта - баш администраторга, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, исемлеккә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Баш администратор баш тартуга китергән сәбәпләрне бетергәннән соң, тәкъдимнәрне кабат җибәрергә хокуклы.»;

2. Әлеге карар 2022 елның гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче С.П. Матвеева